ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА ӘЛЕМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

НОВОАЛИМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423762, Яңа Әлем авылы, Г.Тукай урамы,

55 йорт.

423762, село Новое Алимово, ул.Г.Тукая,

дом 55.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

17.06.2025

КАРАР

№ 11

**Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге хезмәткәрләренең эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 15 февралендәге 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 05 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары турында «Федераль законның 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 338-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Актаныш районы прокуроры вазыйфаларын башкаручының 2025 елның 03 июнендәге 02-08-02-2025/Прдп 175-25-20920005 номерлы протестын карап, Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл башкарма комитеты хезмәткәрләренең эчке хезмәт тәртибе Кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 15 февралендәге 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1. 2.4 пунктта:**

**а) 2 пунктчаны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкета;

**б) 4 пунктчаны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) хезмәт кенәгәсен һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләрне, хезмәт шартнамәсе (контракты) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш; (Федераль законның 31.07.2020 № 268-ФЗ редакциясендә)

**в) 5 пунктчаны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

5) мәгариф һәм квалификация турында документ;»

**д) 14** абзацта «белешмәләр» сүзләреннән соң «(анкетадагы белешмәләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә,

**1.2 2.14 пунктта :**

**а) 4 абзацны** үз көчен югалткан дип танырга.

**б) түбәндәге эчтәлекле абзац** өстәргә:

«- муниципаль хезмәткәрләргә чит ил агенты статусын алу».

**4.2 пунктына** түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетада булган белешмәләрнең мәгълүм үзгәрешләре турында язма формада хәбәр итәргә, моңа яллаучының (эш бирүченең) вәкиле карары буенча үзгәргән белешмәләр керми (алга таба - анкетадагы белешмәләр).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе М.М. Исламов